**Республика Татарстан САКЛОВ-БАШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

22.11.2024 г. — № 95А

Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Сарман муниципаль районының «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
А) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Салым ставкаларын күләмдә билгеләргә:
2.1. 0,1 процентка карата:
2.1.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән;
2.1.2. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;
2.2. 0,2 процентка карата:
2.2.1. фатирлар, фатир өлешләре;
2.2.2. бүлмә;
2.3. 0,3 процентка карата:
2.3.1. торак йорталар, торак йортларның өлешләре;
2.3.2. төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

2.3.3. составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;
2.4. 2 процента карата:
2.4.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
2.4.2. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
2.4.3. һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;
2.4.4. 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата салым салу объектларына карата 2 процент, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
Советы рәисе Габидуллина Л.М.